ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06 апрель 2026 ел

№ 3325

Башкарма комитетның «Үсеш» сәнәгать паркы резидентларын конкурста сайлап алу турында» 2024 елның 19 апрелендәге 2474 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Үсеш» сәнәгать паркы резидентларын конкурста сайлап алу турында» 2024 елның 19 апрелендәге 2474 номерлы Карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтада:

- 19 пунктта 3, 4, 5 пунктчалар үз көчен югалткан дип танырга;

- «Үсеш» сәнәгать паркы резидентларын конкурста сайлап алуны үткәрү турында нигезләмәгә 3 нче кушымта үз көчен югалткан дип танырга;

2) 2 нче кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 6 апрелендәге
3325 номерлы карарына
кушымта

Башкарма комитетның
2024 елның 19 апрелендәге
2474 номерлы карарына
2 нче кушымта

«Үсеш» сәнәгать паркы резидентларын
сайлап алу буенча конкурс комиссиясе
составы

| № т/б | Ф.И.А.и. | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1. | Салахов Фәрид Шавкат улы | конкурс комиссиясе рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе |
| 2. | Кропотова Наталия Анатольевна | конкурс комиссиясе рәисе урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 3. | Пучкин Константин Юрьевич | конкурс комиссиясе секретаре, «Үсеш» СПИК» ЖЧҖ директоры (килешү буенча) |
| конкурс комиссиясе әгъзалары: | | |
| 4. | Бәшәров Фәрид Рәшид улы | «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Сәүдә-сәнәгать палатасы» берлегенең генераль директоры (килешү буенча) |
| 5. | Гыйләҗева Гүзәл Вәлиәхмәт кызы | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы |
| 6. | Зәйнетдинов Гадел Марсель улы | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы урынбасары, эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү бүлеге башлыгы |
| 7. | Миңнегалиев Раил Габделхәй улы | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы депутаты (килешү буенча) |
| 8. | Мулюкова Светлана Рафаиль кызы | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы |
| 9. | Фәттахов Мансур Әдип улы | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева